**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.10.2015 г.Казань № 01-02/734

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кергән гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында» 2015 елның 29 июлендәге 01-02/497 номерлы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы боерыгына үзгәрешләрне кертү турында

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кергән гражданнар һәм оешмалармөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе турында» 2015 елның 29 июлендәге 01-02/497 номерлы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кергән гражданнар һәм оешмалармөрәҗәгатьләренә анализ ясауның боерык белән расланган тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.И.Заһидуллин

Утвержден
приказом министра юстиции
Республики Татарстан
от « 20 » 07 2015
№ 01-02/497
(в редакции приказа
от « 19 » 10 2015
№ 01-02/734 )

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына
кергән гражданнарһәм
оешмалармөрәҗәгатьләренәанализ ясау тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына (алга таба – министрлык) гражданнардан һәм оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасынбилгели.

2. Мөрәҗәгатьләрне электрон документ әйләнеше һәм әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 бүлекләренә туры китереп бирелгән мәгълүмат нигезендә министрлыкның оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге(алга таба - бүлек) гомумиләштерә һәм анализ ясый.

3. Министр, министрның беренче урынбасары, министр урынбасарлары, эшләр идарәчесе (алга таба – министрлык җитәкчелеге, гражданнарны кабул итү буенча вәкаләтле затлар) кабул иткәндәге мөрәҗәгатьләр турында мәгълүматны Бүлеккәминистрлык җитәкчелегенең кабул итүе вакытында гражданнарны язып баручы белгеч тапшыра.

4. Күчмә кабул итүләр турында мәгълүматны Бүлеккә Җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлеге тапшыра.

5. Анализ ясаганда кабул ителгән, башка урынга адресланган һәм каралган язмача мөрәҗәгатьләр, электрон документ әйләнеше формасындагы мөрәҗәгатьләрсаны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итергә вәкаләтле затлар һәм күчмә кабул итүләр, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча күрелгән чаралар, шул исәптән, кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булган очракта) мәгълүмат өйрәнелә.

6. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны җаваплы хезмәткәрләр Бүлеккә яртыеллыкның соңгы аеннан соң килгән айның 10нчы көненә кадәр тапшыра.

7. Бүлек мөдире әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, шулай ук, 3 һәм 4 пунктына туры китереп тапшырылган мәгълүматны ике эш көне эчендә гомумиләштереп анализ ясый да, анализны министрлыкның эшләр идарәчесе белән килештерә.

8. Мөрәҗәгатьләр анализы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыру өчен Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә юллана. Анализ яртыеллыкның соңгы аеннан соң килгән айның 15еннән дә соңга калмыйча, министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

9. Гражданнарның Министрлыкка мөрәҗәгатьләренең анализы Министрлыкның рәсми сайтындагы ачык мәгълүмат булып тора(http://miniust.tatarstan.ru).